**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**УЗЯКСКИЙ СЕЛЬСКИЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

Хазиева ул., д. 8, п. Узяк, 422092
тел. (факс): (84360) 5-22-17,
E-mail: Uzk.Tul@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ҮЗӘК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Хәҗиев ур., 8 нчы йорт, Үзәк бистәсе, 422092
тел. (факс): (84360) 5-22-17,
E-mail: Uzk.Tul@tatar.ru

ОКПО 93053615 ОГРН 1061675010165 ИНН/КПП 1619004370/161901001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**№1** **«01» февраль 2021 г.**

Теләче муниципаль районы Үзәк авыл җирлеге Башкарма комитетының 11.12.2016 елның 28 номерлы «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2021 елның 15 гыйнварындагы 11/13-09/111 номерлы, 2021 елның 22 гыйнварындагы 11/13-09/236 номерлы хатларын карап, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

1. Теләче муниципаль районы Үзәк авыл җирлеге Башкарма комитетының 11.12.2016 елның 28 номерлы «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» карарына (06.05.2020 елның №15 номеры,28.10.2020елның №30 номерлы карар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**1)** Агач һәм куаклар кисүгә, кронировкалауга яки утыртуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламенты:

А) 2.6 пунктны түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә::

«Салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле йөкләмәләрнең булуы яки булмавы турында белешмә (авария хәлләренә бәйле эшләрне башкару очрагында бирелми).».

2.9 пунктының икенче абзацын түбәндәге эчтәлекле 4 пунктча белән тулыландырырга:

«5) Салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле йөкләмәләрнең булуы (авария хәлләренә бәйле эшләрне башкару очрагында бирелми).».

2. Әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

__________________/ В.Н.Котников